СОВЕТ КАНАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

26.02.2018 д. Канаш ___ №36-167

**«Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымы түләү буенча салым ташламалары бирү турында» 2017елның 27 сентябрендәге 30-135 номерлы Канаш авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Югары Ослан прокурорының 2018елның 09гыйнварындагы 02-07-02 номерлы протестын карап, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлегенә таянып,

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә җир салымы түләү буенча салым ташламалары бирү турында» 2017елның 27 сентябрендәге 30-135 номерлы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Әлеге карарның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүчеләр өчен ташламалар эшкуарлык эшчәнлеге өчен файдаланылмый торган, ә берничә җир кишәрлеге (өлешләре) булган җир кишәрлекләре (өлешләре) өчен бары тик бер җир кишәрлеге өчен генә бирелә дип билгеләргә»;

1.2. Әлеге карарның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән салым түләүче-физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гаризаны үз сайлау буенча тапшыра, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый документларны тапшырырга хокуклы»;

2. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы Н.Н.Вальков